РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

16.07.2024 Олы Кайбыч ав. № 274

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2015 елның 21 августындагы 291 номерлы Кайбыч муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында» Федераль законның 12 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 12 декабрендәге 594-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2015 елның 21 августындагы 291 номерлы Кайбыч муниципаль районы Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаның 6 пунктындагы 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15.2 статьясында каралган анкета;»;

- 2 нче кушымтаның 3.6 пунктын түбәндәге эчтәлекле 3.6.10 пунктчасы белән тулыландырырга:

«3.6.10. яллаучының (эш бирүченең) вәкиленә, үзенә мәгълүм булган анкетадагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15.2 статьясында каралган белешмәләрнең мәгълүм үзгәрешләре турында язма рәвештә хәбәр итәргә, моңа яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары буенча үзгәргән белешмәләр керми.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга.

Совет Рәисе,
Кайбыч муниципаль районы Башлыгы А.И.Рәхмәтуллин